DOI: 10.26907/2311-2042-2025-25-2-180-186

# REVIEW OF THE BOOK “WRITERS’ LETTERS FROM THE FRONT: A COLLECTION OF SOLDIER-WRITERS’ LETTERS AND AWARD CERTIFICATES” (KAZAN: TATAR BOOK PUBLISHING HOUSE, 2024. 272 P.)

**Guzel Amirovna Nabiullina,**
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation,
GuzelNab2@yandex.ru.

**Landysh Giniyatovna Latfullina,**
Moscow State Pedagogical University,
1 Malaya Pirogovskaya Str., 119435, Moscow, Russian Federation,
landysh2004@bk.ru.

This article reviews Alfia Shamova’s book “Writers’ Letters from the Front: A Collection of Soldier-Writers’ Letters and Award Certificates” (2024). This large collection, which became the object of this review, is considered from the point of view of its content, structure, scientific, and spiritual value. This work, containing letters from the front and documents – the living memories of the Patriotic War chronicle, helps to revive harsh memories of the terrible forties, as it is imbued with the spirit of the time and the patriotic feelings of Tatar writers, their faith in our victory over the enemy.

**Key words**: Tatar literature, Tatar writers, Great Patriotic War, Tatar military press, front-line letters

**For citation:** Nabiullina, G., Latfullina, L. Review of the book “Writers’ Letters from the Front: A Collection of Soldier-Writers’ Letters and Award Certificates” (Kazan: Tatar Book Publishing House, 2024. 272 p.) // Tatarica. 2025. No. 2 (25), pp. 180–186; https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-180-186

The theme of the Great Patriotic War in literature is a historical memory of those terrible years, of the heroic deeds performed by the immortal sons and daughters who defended the independence of our Motherland. This topic remains relevant today: life reveals new, previously unknown memories and sources, enriching the history of the great deeds of the Soviet people.

It is well-known that 124 Tatar writers took part in the Great Patriotic War, 34 of them died in the battlefield [1, p. 6]. According to the research of historian A. Kabirova, 25 of the 53 writers, members of the Writers’ Union, went to the front in the first year of the war [2, p. 396]. “Tatar writers contributed to the glorious victory not only with bullets aimed at the enemy, but also with their pens. M. Jalil, F. Karim, A. Alish, G. Kutuy, N. Bayan, K. Basyrov and others gave their lives for this historic victory, which ensured the freedom of our Motherland and a happy future for our people! During the war, Tatar writers and poets, walking on a knife’s edge, maintained constant correspondence. These letters clearly testify to their enormous faith in our victory over the enemy, their concern for the state of literature, the fate of their fellow writers, and their mutual creative friendship even in those difficult times” [3].

Faded and yellowed with age, front-line letters, stamped with field postmarks, are priceless documents, the living relics of the Great Patriotic War, preserving the harsh memory of the “dashing forties.” Some of these historical sources were published in the Tatar press over the years, but the majority are preserved in state archives, museum collections, and, rarely, in the hands of private individuals, like precious heirlooms in family archives.

Every historical fact, every document, every piece of evidence in the living memory of the Great Patriotic War are of particular value. In our republic, war letters have been collected and published in collections since 1943. The first collection was prepared and published by the State

Archive employee S. Kirsanov [4]. In 1946, letters from the front could be found in a collection compiled by A. Tarasov and Kh. Gimadi [5]. In 2003, the book “They All Wanted to Live” [6] was published, compiled by N. Frolov and based on sources stored in the archives of the Cheremshansky District. The book consists of letters, memoirs, and documents. Most of the letters are written in the Tatar language, often using Arabic and Latin scripts.

In 1998, the Publishing House “Otechestvo” released the collection “Frontovoe pismo – Front khaty” (“A Frontline Letter”) [7]. The booklet presents letters, photographs, and the text of several documents from the Great Patriotic War in Russian and Tatar. The documents were collected during Operation “A Frontline Letter” by the “Snow Landing” search teams of Kazan State Pedagogical University and the “Vatan” (“Fatherland”) search team of the History Department, Kazan State University. They were found in the collections of the State Museum of the Republic of Tatarstan, and provided by residents of the Republic. The illustrations include samples of letters, postcards, identification cards, etc.

In 2010, the National Archives compiled and published a collection entitled “Letters from the Front. 1941–1945”. [8] The collection includes front-line letters from such famous writers as Musa Jalil, Fatih Karim, Mikhail Bubennov, Adel Kutuy, Gennady Paushkin, and others.

In 2014, Alfiya Shamova, the daughter of the renowned writer Afzal Shamov, compiled and published a collection of letters and award certificates sent from the front by Tatar writers who had participated in the war. The book contains over 500 letters [9]. In 2024, this book was slightly abridged and republished by the Tatar Book Publishing House under the title “Writers’ Letters from the Front: A Collection of Soldier-Writers’ Letters and Award Certificates” [10].

These letters from Tatar front-line writers, included in the book, were provided by: 1) the National Archive of the Republic of Tatarstan; 2) the Center for Written and Musical Heritage of the G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Arts of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan; 3) the National Museum Fund of the Republic of Tatarstan; 4) personal funds of writers (Afzal Shamov, Gabdrakhman Apsalyamov, and Mirsai Amir); 5) letters published in print.

The collection includes letters from 39 Tatar writers who participated in the Patriotic War, among them: Musa Jalil, Abdullah Alish, Nur Bayan, Miftah Vadut, Fatih Karim, Kasym Vakhit, Adel Kutuy, Kashfi Basirov, and Demyan Fathi. The collection includes letters from Rakhman Ilyas, Iskhak Zakirov, Khatip Gusman, Gabdrakhman Apsalyamov, Muhamed Sadri, Garif Galiev, Shaikhi Mannur, G.-Khalik Sadri, Sharaf Mudarris, Atilla Rasikh, Sibgat Khakim, Abdulla Akhmet, Afzal Shamov, Gumer Bashirov, Akhmet Erikey, Ibrahim Ghazi, Gali Khudzhi, Anvar Davydov, Fatih Khusni, Riza Ishmurat, Nuri Arslanov, Gamir Nasri, Idris Tuktar, Khassan Khairi, Gusman Bakirov, Akhmet Fayzi, Asgat Aydar, Gaziz Idelle, and Makhmut Khusain. These letters are addressed to pen pals from one front to the other front and to the rear, to the Writers’ Union, and to literary critics. The authors of these letters are eleven outstanding heroes who sacrificed their lives for their homeland: Musa Jalil, Abdullah Alish, Fatih Karim, Nur Bayan, Adel Kutuy, Rakhman Ilyas, Kashfi Basirov, Miftah Vadut, Kasym Vakhit, Ishak Zakirov, and Demyan Fathi. The book contains 35 certificates of orders and medals awarded to the writers for bravery at the front, brief information about the authors, artists, and scholars, and important notes in the footnotes.

The letters from frontline writers, published in this collection, are of immense spiritual value. These frontline letters capture the spirit and patriotic feelings of the time, imbued with a tremendous faith in our victory over the enemy. These letters, written on a shovel, a boot, or the bottom of a mess tin, can be divided into two groups. In the first group, there are official letters: frontline writers, concerned about their families and their work, primarily addressed the Soviet authorities, the trade union leaders, and the editor of the journal “Soviet Literature.” At the same time, they also sent letters requesting materials for publication in newspapers, published at the front. As we know, the writer, literary scholar, and educator Kh. Gusman, like most members of Tatar intelligentsia, was sent to the front from the first days of the war. He served on the front lines as a war correspondent for frontline newspapers, as an officer in a sapper brigade, and met the end of the war in the German town of Güstropht. During the war years, he did not forget about literary work: he compiled a collection of frontline notes, “On the Line of Fire,” and wrote the story “A Fiery Heart.” This collection contains letters from Kh. Gusman to G. Kashshaf, Kh. Yarmi, T. Gizzat, M. Amir, G. Bashirov, and others, giving an idea of the writer’s tireless creative work at the front. For example, on November 21, 1943, he wrote to G. Kashshaf,

concerned about the fate of his works: *"I have sent you the collection "On the Line of Fire"... When will you publish it? My wife will draw up the contract. A letter of confidence has been sent to her"* [10, p. 82].

The second group consists of letters from writers to their colleagues. Tatar writers, who at every opportunity wrote and created literary works even under a hail of fire, during bomb explosions, or during brief periods of silence, inspired their comrades to perform great deeds with their fiery words. Although written in flames, "they contain no tears of lamentation, no sadness, no pain, no groans". Even in times of terror, writers shared their literary plans and thoughts on the future of Tatar literature, expressed concern for the fate and work of their fellow writers, conveying feelings of creative friendship and aspirations. We know that the writer, publicist, and public figure A. Kutuy was called to the front in 1942. During the Great Patriotic War, he wrote numerous articles for foreign countries through the Soviet Information Bureau and spoke on Moscow Radio. For his bravery and service at the front, he was awarded the Order of the Patriotic War, 2nd class, the Order of the Red Star, and medals. The collection includes letters from A. Kutuy to A. Shamov, T. Gizzat, G. Kashshaf, K. Nadzhmi, G. Bashirov, and others. In a letter to G. Bashirov dated January 1, 1945, he wrote: *"I'm so eager to write... I want to defeat the damned Germans as soon as possible, and then roll up my sleeves and write. I wish these days would come soon!"* [10, p. 57].

The content of the letters is clearly influenced by the censorship and ideological attitudes of the time. A. Shamova's preface provides the following explanation: "At the beginning of the war, some Tatar writers wrote letters from the front in Russian, since due to censorship, they took a week or ten days to arrive; in Tatar, about a month; while in Arabic, three months" [10, p. 4].

Most of the letters, included in the collection, have been published for the first time. Some letters, known to the general public, are presented in full. For example, the full text of M. Jalil's letter to G. Kashshaf, dated June 3, 1942, has been published for the first time [pp. 10, 13].

The collection is enriched with photographs. The appendix contains useful material: a table entitled "Information on frontline newspapers published in the Tatar language during the Great Patriotic War" [10, pp. 257–258]. The list of writers who worked for the newspapers deserves special attention [10, p. 259].

Frontline letters by Tatar writers demonstrate a breadth of content and a diversity of perspectives in plot construction. The content of the letters and their internal logic are closely linked to factors of personal and combat situations. These triangular frontline letters, filled with longing for the homeland, hatred of the enemy, dark sorrow, and tears, will preserve historical memory, passing it on from generation to generation. Frontline memoirs, frontline photographs, letters from frontline soldiers, and frontline newspapers – all of them require detailed scholarly study.

We, agreeing with historian A. Ivanov's opinion, consider front-line epistolary documents in the regions to be valuable sources that can serve as a basis for studying the dynamics of changes in the political consciousness of soldiers during the war years [11, p. 23], the features of the "dialogue" between the authorities and society, and the literary lives of Tatar writers.

**References**

1. *Tatarstannyn frontovik yazuchylary* (2016) [Tatarstan Frontline Writers]. Sost. Sh. Mustafin, F. Mushinskiy. 367 p. Kazan, Tatar. kit. nashr. (In Tatar)

2. Kabirova, A. Sh. (2013). *Tatarskaya ASSR – vazhnaya tylovaya baza SSSR* [The Tatar ASSR Is an Important Rear Base for the USSR]. Istoriya tatar s drevneishikh vremen: v semi tomakh. T. VII. Tatary i Tatarstan v 20 – nachale 21 v. Pp. 388–398. Kazan, Institut Istorii Akademii nauk respubliki Tatarstan. (In Russian)

3. *Fronttan khatlar* (1958) [Letters from the Front-line]. Pp. 76–81. Sovet ədəbiyəty. No. 2. (In Tatar)

4. *Pis'ma s fronta: Urozhentsy Tatarii – uchastniki Velikoi Otechestvennoi voiny s Germaniei* (1943) [Letters from the Front: Natives of Tatarstan – Participants in the Great Patriotic War with Germany]. 43 p. Kazan, Tatgosizdat. (In Russian)

5. *V boyakh za nashu Sovetskuyu Rodinu: (Sbornik dokumentov Velikoi Otechestvennoi vojny)* (1946) [In the Battles for Our Soviet Motherland: (Collection of Documents of the Great Patriotic War)]. A. Tarasov, Kh. Gimadi; Kazan. filial Akad. nauk SSSR. In-t yazyka, lit-ry i istorii. 136 p. Kazan, Tatgosizdat, Kn. f-ka im. Kamil' Yakub. (In Russian)

6. *Vse oni khoteli zhit': Frontovye pis'ma, vospominaniya, fotogr., dokumenty iz fondov Cheremshan. Memorial. tsentra* (2003) (They All Wanted to Live: Front-line Letters, Memoirs, Photographs, Documents from the Cheremshan Memorial Center Collections). Sost. N. S. Frolov. 255 p. Kazan, TaRIKH. (In Russian)

7. *Frontovoe pismo – Front khaty* (1998) [A Frontline Letter]. 72 p. Kazan, Otechestvo. (In Russian)

8. *Pis'ma s fronta. 1941–1945 gg.: sbornik dokumentov* (2010) [Letters from the Front. 1941–1945: A Collection of Documents]. Gl. arhivnoe upr. pri Kab. Ministrov Resp. Tatartan, Central'nyi gos. arhiv istoriko-politicheskoi dokumentatsii Resp. Tatarstan, Nats. Arhiv Resp. Tatarstan (sost. D. I. Ibragimov i dr.). 230 p. Kazan, Gasyr. (In Russian)

9. *Sugysh uty belən өtelgan yazmyshlar: ike kitapta. – Berenche kitap: Frontovik yazuchylarnyn hatlary həm bulaklau kagaz'lare zhyentygy* (2014) [Fates Engulfed in the Flames of War: In Two Books. – Book One: A Collection of Letters and Award Documents from Frontline Writers]. Sost. A. Shamova; red. F. Zhaukharova]. 623 p. Kazan, Ikhlas. (In Tatar)

10. *Ədiplərnen front kharlary: frontovik yazuchylarnyn hatlary həm buləkləү kəgaz'laəre zhyentygy* (2024) [Front Letters of Writers: A Collection of Letters and Award Documents from Frontline Writers]. Sost. A. Shamova. 272 p. Kazan. Tat. kit. nashr. (In Tatar)

11. Ivanov, A. Yu. *Frontovye pis'ma uchastnikov Velikoi Otechestvennoi voiny kak istoricheskii istochnik: po materialam Respubliki Tatarstan: avtoreferat dis.. ... kand. ist. nauk:* (2009) [Front-line Letters from Participants in the Great Patriotic War as a Historical Source: Based on Materials from the Republic of Tatarstan: Ph.D. Thesis Abstract]. Kazan, 24 p. (In Russian)

# «ӘДИПЛӘРНЕҢ ФРОНТ ХАТЛАРЫ» (КАЗАН: ТАТАР. КИТ. НӘШР., 2024. 272 Б.) ҖЫЕНТЫГЫНА БӘЯЛӘМӘ

**Гүзәл Әмировна Нәбиуллина,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 йорт,
GuzelNab2@yandex.ru.

**Ландыш Гыйният кызы Латфуллина,**
Мәскәү дәүләт педагогия университеты,
Россия, 119435, Мәскәү ш., Малая Пироговская ур., 1 нче йорт,
landysh2004@bk.ru.

Тәкъдим ителгән мәкаләдә Әлфия Шамова тарафыннан төзелгән «Әдипләрнең фронт хатлары: фронтовик язучыларның хатлары һәм бүләкләү кәгазьләре җыентыгы» дип аталган китапка (2024) күзәтү ясала. Бәяләү объекты итеп алынган саллы җыентык эчтәлеге, төзелеше, фәнни һәм рухи кыйммәтләре ягыннан тикшерелә. Чор сулышын һәм татар язучыларының ватанпәрвәрлек хисләре, дошманны җиңүгә зур ышаныч белән сугарылган фронт хатларын, документларын – Ватан сугышы елъязмасының җанлы истәлекләрен туплаган бу хезмәт дәһшәтле кырыгынчы елларның кырыс чынбарлыгын күзалларга ярдәм итә.

**Төп төшенчәләр**: татар әдәбияты, татар язучылары, Бөек Ватан сугышы, татар хәрби матбугаты, фронт хатлары

**Сылтама өчен:** Нәбиуллина Г.Ә., Латфуллина Л.Г. «Әдипләрнең фронт хатлары» (Казан: Татар. кит. нәшр., 2024. 272 б.) җыентыгына бәяләмә // Tatarica. 2025. № 2 (25). 180–186 б. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-180-186

Әдәбиятта Бөек Ватан сугышы темасы – дәһшәтле еллар, Ватаныбызның бәйсезлеген саклап калган үлемсез ул һәм кызларның батырлыклары турындагы тарихи истәлек. Бу тема бүген дә үзенең актуальлеген югалтмый: тормыш безгә моңа кадәр мәгълүм булмаган яңа хатирәләр һәм чыганаклар ача, совет халкының бөек гамәлләр тарихын баета.

Билгеле булганча, Бөек Ватан сугышында 124 татар язучысы катнаша, шуларның 34 е сугыш кырында ятып кала [1, б. 6]. Тарих фәннәре докторы А.Ш. Кәбирова тикшере-нуләренә караганда, сугышның беренче елында Язучылар берлегендә торган 53 язучыдан 25 е фронтка китә [2, б. 396]. «Татар язучылары дошманга төзәп аткан пулялары белән генә түгел, каләмнәре белән дә данлы җиңүгә үз өлешләрен керттеләр. М. Җәлил, Ф. Кәрим, А. Алиш, Г. Кутуй, Н. Баян, К. Басыйров һәм башкалар Ватаныбызга азатлык, халкыбызга бәхетле киләчәк тәэмин иткән бу тарихи җиңү өчен башларын салдылар! Сугыш елларында ут эчендә йөрүче татар язучылары, шагыйрьләре бер-берләре белән даими рәвештә хат язышып тордылар. Бу хатларда аларның

дошманны җиңүгә зур ышанычлары, шундый авыр көннәрдә дә әдәбиятның торышы, каләмдәш иптәшләренең язмышы турында кайгыртып торулары, үзара һәм иҗади дуслыклары ачык күренә» [3].

Вакыт үтү белән уңып һәм саргаеп беткән, кыр почтасы штемпеле сугылган фронт хатлары – бәяләп бетергесез документлар, «дәһшәтле кырыгынчы» елларның кырыс истәлеген саклаган Бөек Ватан сугышы елъязмасының җанлы истәлекләре. Бу тарихи чыганакларның кайберләре төрле елларда татар матбугаты битләрендә дөнья күрде, күбесе дәүләт архивларында, музей фондларында, һәм сирәк кенә аерым кешеләр кулында кадерле истәлек булып гаилә архивларында саклана.

Бөек Ватан сугышы чорына караган һәр тарихи факт, һәр документ, һәр җанлы истәлек аеруча кадерле. Республикабызда сугыш хатларын 1943 нче елдан җыентык итеп туплап бастыра башлыйлар. Беренче җыентык Дәүләт архивы хезмәткәре С.И. Кирсанов тарафыннан әзерләп бастырыла [4]. 1946 нчы елда А. Тарасов, Х. Гыймади төзегән тупланмада фронт хатлары белән танышырга мөмкин [5]. 2003 нче елда Н.С. Фролов тарафыннан Чирмешән районы архивларында сакланган чыганаклар нигезендә төзелгән «Все они хотели жить» дигән китап [6] дөнья күрә. Китап хатлардан, хатирәләрдән, документлардан тора. Хатларның күбесе татар телендә, еш кына гарәп һәм латин графикасын кулланып язылган.

1998 нче елда «Отечество» нәшриятында «Фронтовое письмо – Фронт хаты» исемле җыентык [7] дөнья күрә. Әлеге брошюрада Бөек Ватан сугышы чорындагы хатлар, фотосурәтләр һәм рус, татар телләрендә кайбер документларның текстлары бирелгән. Документлар «Фронт хаты» акциясе барышында КДПУның «Карлы десант» («Снежный десант») эзләү отрядлары һәм КДУның тарих факультеты, «Ватан» («Отечество») эзләү төркеме сугышчылары тарафыннан җыелган, ТР Дәүләт музее фондларыннан алынган, шулай ук республика халкы тарафыннан тапшырылган. Иллюстрацияләр арасында хат үрнәкләре, почта карточкалары, грамоталар һ. б. очратырга мөмкин.

2010 нчы елда Милли архив тарафыннан «Письма с фронта. 1941-1945 гг.» [8] исемле җыентык төзеп бастырыла. Документлар арасында Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Михаил Бубеннов, Гадел Кутуй, Геннадий Паушкин һ. б. күренекле әдипләрнең фронт хатлары урын ала.

2014 нче елда күренекле язучы Афзал Шамовның кызы Әлфия Шамова сугышта катнашкан татар язучыларының фронттан юллаган хатларын һәм бүләкләү кәгазьләрен туплап, җыентык төзеп бастыра. Анда 500 дән артык хат урнаштырылган [9]. 2024 нче елда бу китап берникадәр кыскартылып, «Әдипләрнең фронт хатлары: фронтовик язучыларның хатлары һәм бүләкләү кәгазьләре җыентыгы» исеме белән Татар китап нәшриятында кабат дөнья күрә [10].

Китапка кертелгән татар фронтовик язучылары язган хатларның чыганаклары берничә: 1) Татарстан Республикасының Милли архивы; 2) Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге; 3) Татарстан Республикасының Милли музей фонды; 4) Язучыларның шәхси фондлары (Афзал Шамов, Габдрахман Әпсәләмов, Мирсәй Әмир); 5) Матбугат битләрендә дөнья күргән хатлар.

Җыентыкта Ватан сугышында катнашкан 39 татар язучысы – Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Нур Баян, Мифтах Вәдүт, Фатих Кәрим, Касыйм Вахит, Гадел Кутуй, Кәшфи Басыйров, Демьян Фәтхи. Рахман Ильяс, Исхак Закиров, Хатип Госман, Габдрахман Әпсәләмов, Мөхәммәт Садри, Гариф Галиев, Шәйхи Маннур, Г.-Халикъ Садри, Шәрәф Мөдәррис, Атилла Расих, Сибгат Хәким, Абдулла Әхмәт, Афзал Шамов, Гомәр Бәширов, Әхмәт Ерикәй, Ибраһим Гази, Гали Хуҗи, Әнвәр Давыдов, Фатих Хөсни, Риза Ишморат, Нури Арсланов, Гамир Насрый, Идрис Туктар, Хәсән Хәйри, Госман Бакиров, Әхмәт Фәйзи, Әсгать Айдар, Газиз Иделле, Мәхмүт Хөсәен хатлары урын алган. Бу хатлар фронттан фронтка, һәм тылга каләмдәш дусларына, Язучылар берлегенә, әдәбият галимнәренә адресланган. Хат авторлары арасында Ватаныбыз өчен гомерләрен биргән 11 тиңдәшсез батыр – Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Фатих Кәрим, Нур Баян, Гадел Кутуй, Рахман Ильяс, Кәшфи Басыйров, Мифтах Вәдүт, Касыйм Вахит, Исхак Закиров, Демьян Фәтхи дә бар. Китапта язучыларга фронтта күрсәтелгән батырлыкларына мөнәсәбәтле бирелгән орден-медальләрнең 35 бүләкләү кәгазе урнаштырылган, әдипләр, сәнгать осталары, галимнәр турында кыскача белешмә, астөшермәләрдә әһәмиятле искәрмәләр урын ала.

Җыентыкта басылган фронтовик язучыларның хатлары гаять зур рухи кыйммәткә ия. Язучыларның фронт хатлары шул чорның

сулышын һәм ватанпәрвәрлек хисләрен саклаган, дошманны җиңүгә зур ышаныч белән сугарылган. Кәгазен көрәккә, я итек кунычына, я котелок төбенә куеп язылган бу хатларны ике төркемгә бүлергә мөмкин. Беренче төркемгә кергән рәсми хатларда, беренче чиратта, фронтовик язучылар, үз гаиләләрен, иҗатларын кайгыртып, совет органнарына, берлек җитәкчесенә, «Совет әдәбияты» журналы мөхәрриренә мөрәҗәгать итәләр. Шул ук вакытта алар фронтта чыга торган газеталарга бастыру өчен, материал сорап та хатлар юллыйлар. Мәгълүм булганча, язучы, әдәбият галиме, педагог Х. Госман күпчелек татар зыялылары кебек, сугышның беренче көннәреннән үк фронтка озатыла, фронт газеталарының хәрби корреспонденты, саперлар бригадасы офицеры сыйфатында алгы сызыкта булып, сугышны Алманиянең Гюстроф шәһәрендә тәмамлый. Сугыш елларында әдәби иҗатын да онытмый: «Ут сызыгында» дигән фронт язмалары җыентыгын төзи һәм «Ялкынлы йөрәк» дигән повестен яза. Әлеге тупланмада Х. Госманның Г. Кашшафка, Х. Ярмигә, Т. Гыйззәткә, М. Әмиргә, Г. Бәшировка һ.б. язган хатлары урын ала, бу хатлар әдипнең фронттагы тынгысыз иҗади эшчәнлеген күзалларга мөмкинлек бирә. Мисал өчен, 1943 нче елның 21 нче ноябрендә Г. Кашшафка ул, әдәби әсәрләре язмышы өчен борчылып, болай дип яза: «*Мин сезгә “Ут сызыгында” дигән җыентык җибәргән идем... Аны кайчан басып чыгарасыз? Договорны минем хатын төзер. Аңа ышаныч язуы җибәрелгән*» [10, б. 82]

Икенче төркемгә язучыларның каләмдәш иптәшләренә язган хатлары керә. Ут яңгыры астында да, бомбалар шартлаганда да, яисә кыска гына тынлык вакытларында да язарга, иҗат итәргә мөмкинлек тапкан татар язучылары бу хатларда ялкынлы сүзләре белән көрәштәшләрен зур батырлыкларга рухландырган. Ут эчендә язылган булсалар да, «аларда зар, моңсулык, әрнү, сыкрануның да әсәре дә юк». Каләм ияләре дәһшәтле көннәрдә дә татар әдәбиятының киләчәге турындагы әдәби планнары һәм фикерләре белән уртаклашалар, каләмдәшләренең язмышы, иҗаты турында кайгырталар, үзара иҗади дуслык хисләрен, омтылышларын җиткерәләр. Белгәнебезчә, язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе Г. Кутуй 1942 нче елны сугышка алына. Бөек Ватан сугышы вакытында ул Совинформбюро буенча чит ил өчен күп мәкаләләр яза, Мәскәү радиосыннан чыгышлар ясый. Фронтта күрсәткән батырлыклары һәм хезмәтләре өчен, ул II дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл йолдыз орденнары һәм төрле медальләр белән бүләкләнә. Җыентыкта Г. Кутуйның А. Шамовка, Т Гыйззәткә, Г. Кашшафка, К. Нәҗмигә, Г. Бәшировка һ. б. язган хатлары урын ала. 1945 нче елның 1 гыйнварында Г. Бәшировка язган бер хатында ул болай ди: «*Язасы килә дә соң... Каһәрләнгән немецларны тизрәк җиңеп кайтасы иде дә, җиң сызганып язып утырасы иде. Тизрәк җитсен иде шул көннәр!*» [10, б. 57].

Хатларның эчтәлегенә цензура һәм чорның идеологик күрсәтмәләре йогынты ясаганы ачык күренә. Ә. Шамованың кереш сүзендә мондый аңлатма бирелә: «Сугыш башында кайбер татар язучылары фронттан хатны рус телендә яза, чөнки цензура аркасында алар атна-ун көн, татар телендәгеләр бер ай чамасы, гарәп графикасындагылары өч айлап йөргәннәр» [10, б. 4].

Җыентыкта урын алган хатларның күбесе беренче тапкыр әйләнешкә кертелә. Киң җәмәгатьчелеккә билгеле кайбер хатлар исә тулы вариантта тәкъдим ителә. Мәсәлән, М. Җәлилнең 1942 нче елның 3 нче июнендә Г. Кашшафка язган хатының тулы тексты беренче тапкыр бастырыла [10, б. 13].

Җыентыкның эчтәлеге фотоматериаллар белән баетылган. Китапның кушымтасында да файдалы материал урын алган: таблица рәвешендә «Бөек Ватан сугышы елларында татар телендә чыккан фронт газеталары турында белешмә» бирелгән [10, б. 257–258]. Газеталарда эшләгән язучыларның исемлеге дә аерым игътибарга лаек [10, б. 259].

Татар язучыларының фронт хатлары сюжет төзү ягыннан эчтәлекнең киңлеген һәм фикер-карашлар төрлелеген күрсәтә. Хатларның эчтәлеге, шулай ук аның эчке мантыйгы шәхси һәм хәрби мохит факторлары белән тыгыз бәйләнгән. Туган якны сагыну, дошманга нәфрәт, кара кайгы, күз яшьләре белән сугарылган өчпочмаклы фронт хатлары буыннар артыннан буыннарны алмаштыра-алмаштыра тарихи хәтерне саклаячак. Сиксән елдан артык вакыт эчендә дәһшәтле елларның михнәтен, ачысын, ватанпәрвәрлек хисләрен җуймаган фронт истәлекләрен, фронтта төшерелгән рәсемнәрне, фронтовик хатларын, фронт газеталарын – боларның барысын да фәнни яктан җентекләп өйрәнү сорала.

Без, тарихчы А.Ю. Ивановның фикеренә кушылып, төбәкләрдәге фронт эпистоляр документларын, сугыш елларында солдатларның сәяси үзаңы үзгәрү динамикасын [11, б.

23], хакимият белән җәмгыять арасындагы «диалог» үзенчәлекләрен, шулай ук татар язучыларының әдәби тормышын өйрәнү өчен нигез булып тора алырлык кыйммәтле чыганаклар дип саныйбыз.

**Әдәбият**


1. Татарстанның фронтовик язучылары / төз.: Ш. Мостафин, Ә. Мушинский. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. 367 б.
2. *Кабирова А.Ш.* Татарская АССР – важная тыловая база СССР // История татар с древнейших времен: в семи томах. Т. VII. Татары и Татарстан в XX – начале XXI в. Казань: Институт истории АН РТ, 2013. С. 388–398.
3. Фронттан хатлар // Совет әдәбияты. 1958. №2. Б. 76–81.
4. Письма с фронта: Уроженцы Татарии – участники Великой Отечественной войны с Германией. Казань: Татгосиздат, 1943. 43 с.
5. В боях за нашу Советскую Родину: (Сборник документов Великой Отечеств. войны) / А. Тарасов, Х. Гимади; Казан. филиал Акад. наук СССР. Ин-т языка, лит-ры и истории. Казань: Татгосиздат: Кн. ф-ка им. Камиль Якуб, 1946. 136 с.
6. Все они хотели жить: Фронтовые письма, воспоминания, фотогр., документы из фондов Черемшан. Мемориал. центра / [Сост. Фролов Н.С.]. Казань: ТаРИХ, 2003. 255 с.
7. Фронтовое письмо – Фронт хаты: сборник. Казань: Отечество, 1998. 72 с.
8. Письма с фронта. 1941–1945 гг.: сборник документов / Гл. архивное упр. При Каб. Министров Респ. Татартан, Центральный гос. Архив историко-политической документации Респ. Татарстан, Нац. Архив Респ. Татарстан [сост. Д.И. Ибрагимов и др.]. Казань: Гасыр, 2010. 230 б.
9. Сугыш уты белән өтелгән язмышлар: ике китапта. – Беренче китап: Фронтовик язучыларның хатлары һәм бүләкләү кәгазьләре җыентыгы / [төз. һәм аңлатмалар язучы Ә. Шамова; мөх-р Ф. Җәүһәрова]. Казан: Ихлас, 2014. 623 б.
10. Әдипләрнең фронт хатлары: фронтовик язучыларның хатлары һәм бүләкләү кәгазьләре җыентыгы / [авт.-төз.; кереш сүз авт. Ә. Шамова] Казан: Татар. кит. нәшр., 2024. 272 б.
11. *Иванов. А. Ю.* Фронтовые письма участников Великой Отечественной войны как исторический источник: по материалам Республики Татарстан: автореферат дис. ... канд. ист. наук: 07.00.09. [Место защиты: Казан. гос. ун-т]. Казань, 2009. 24 с.


---

# РЕЦЕНЗИЯ НА КНИГУ «ФРОНТОВЫЕ ПИСЬМА ПИСАТЕЛЕЙ»: (КАЗАН: ТАТАР. КН. ИЗД-ВО, 2024. 272 С.)


**Гузаль Амировна Набиуллина**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
GuzelNab2@yandex.ru.

**Ландыш Гиниятовна Латфуллина,**
Московский педагогический государственный университет,
Россия, 119435, г. Москва, ул. Малая Пироговская, д. 1,
landysh2004@bk.ru.



В данной статье представлен обзор книги Альфии Шамовой «Әдипләрнең фронт хатлары: фронтовик язучыларның хатлары һәм бүләкләү кәгазьләре җыентыгы» (2024). Это документальное издание рассматривается с точки зрения содержания, структуры, научной и духовной ценности. В книге собраны фронтовые письма, документы – живые воспоминания летописи Великой Отечественной войны, проникнутые духом времени и патриотическими чувствами татарских писателей, верой в победу над врагом. Эти материалы помогают представить суровую жизнь страшных сороковых годов.



**Ключевые слова**: татарская литература, татарские писатели, Великая Отечественная война, татарская военная печать, фронтовые письма

**Для цитирования**: Набиуллина Г. А., Латфуллина Л. Г. Рецензия на книгу «Фронтовые письма писателей»: (Казан: Татар. кн. изд-во, 2024. 272 с.) // Tatarica. 2025. № 2 (25). С. 180–186. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-180-186